**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Урта Камышлы авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 94** **21 февраль 2020 ел**

**Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 октябрендәге 47 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 октябрендәге 47 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына (Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 декабрендәге 90 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 Карарның 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендә кабул ителгән «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата "- 0,3 %»;

1.2. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фонды һәм торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаучы объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган

индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)- 0,18 %».

1.3. 4 нче пунктны төшереп калдырырга;

1.4. 5 нче пунктның 2 нче абзацын төшереп калдырырга;

1.5. 7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ташламаларына, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калынган салым ташламасына хокуклы салым түләүчеләр салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, алар шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы»;

1.6. 8 нче пунктны төшереп калдырырга;

1.7. 9 пунктта "законда билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен "билгеләнгән тәртиптә" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 нче статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1.3 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакыт узу белән.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге
Советы рәисе                                        Баймяшкина Н.А.